**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№ 4569**
**14.08.2018 ел**

Муниципаль мөлкәттәге җир кишәрлеген
мөлкәткә бушлай бирү буенча муниципаль
хезмәтләр күрсәтүнең административ
регламентына үзгәрешләр
кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның 2011 елның 30 мартындагы 1576 нчы карары белән расланган Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләрнең административ регламентын эшләү һәм раслау тәртибе турында нигезнамә нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2015 елның 8 сентябрендәге 5034 нче карары белән (Башкарма комитетның 2016 елның 23 июнендәге 3208 нче карары редакциясендә) муниципаль мөлкәттәге җир кишәрлеген мөлкәткә бушлай бирү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.4 пунктында:

- унынчы һәм унберенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге Вәкиллекле органының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 нче карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – шәһәр Уставы) (Челнинские известия, №235-237, 10.12.2005, № 249-250, 30.12.2005) белән;

Башкарма комитетның 2017 елның 28 декабрендәге 1210-р нчы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе турындагы нигезнамәсе белән (алга таба – ҖММИ турындагы нигезнамә)»;

- ундүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Башкарма комитетның 2016 елның 13 маендагы 2363 нче карары белән расланган Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеге (алга таба – Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеге) белән);»;

3) 2.9. пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки баш тарту өчен | Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Баш тарту өчен нигезләр:<br>1) җир кишәрлеге бирү хакындагы гариза белән җир турындагы законнар нигезендә җир кишәрлеген сатулар | РФ ҖКның 39.16 маддәсе |

| | | |
|---|---|---|
| нигезләрнең тулы исемлеге | үткәрмичә сатып алуга хокукы булмаган зат мөрәҗәгать итә;<br>2) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада җир кишәрлегенең даими (сроксыз) файдалануга, түләүсез файдалануга бирелүе, гомерлеккә мираска калуы яки арендага алынган биләмәләр хокукында бирелүе күрсәтелсә, җир кишәрлеге бирү хакындагы гариза белән әлеге хокукларга ия булган зат мөрәҗәгать иткән очрактан кала яисә гариза РФ Җир кодексының 39.10 маддәсе 2 пункты 10 пунктчасы нигезендә бирелгән булса;<br>3) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада җир кишәрлеге яшелчә, җиләк-җимеш бакчалары, дача хуҗалыклары яки шәхси төзелеш максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен гражданнар тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешмаларга бирелүе күрсәтелсә, гариза белән әлеге коммерцияле булмаган оешма әгъзасы яисә коммерцияле булмаган оешма мөрәҗәгать иткән очрактан кала, әгәр җир кишәрлеге гомуми файдаланудагы мөлкәткә караса;<br>4) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада әлеге җир кишәрлегендә гражданнарга һәм юридик затларга караган бина, корылма, тәмамланмаган төзелеш объекты булу күрсәтелсә, корылма (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган корылма) җир кишәрлегендә сервитут шартларында урнашкан яки җир кишәрлегендә РФ Җир кодексының 39.36 маддәсе 3 пунктында каралган объект урнашкан очраклардан кала, һәм бу җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану комачаулык итмәсә яисә җир кишәрлеге бирү хакындагы гариза белән әлеге биналар, корылмалар, алар эчендәге бүлмәләр, әлеге төзелеше тәмамланмаган объектның милекчесе мөрәҗәгать итсә;<br>5) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада әлеге җир кишәрлегендә дәүләт яки муниципаль мөлкәткә караган бина, корылма, тәмамланмаган төзелеш объекты урнашкан булу күрсәтелсә, корылма (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган корылма) җир кишәрлегендә сервитут шартларында урнашкан яисә җир кишәрлеге бирү хакындагы гариза белән әлеге биналар, корылмалар, алар эчендәге бүлмәләр, әлеге төзелеше тәмамланмаган объектның милекчесе мөрәҗәгать итсә;<br>6) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада әлеге җир кишәрлегенең әйләнештән алынганлыгы яки әйләнештә чикләнүе күрсәтелсә, җир кишәрлеге бирү хакындагы гаризада аңа хокук бирүгә юл куелмый<br>7) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен резерланган очракта, әгәр гариза бирүче җир кишәрлеген мөлкәткә, аны резервлау хакындагы карарның гамәлдә булу срогыннан артык срокка бирү турында гариза белән мөрәҗәгать итсә, җир кишәрлеген резервлау максатларында бирү очрагыннан кала;<br>8) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән | |

| | | |
|---|---|---|
| | җир кишәрлеге төзелгән территорияне үстерү турында башка зат белән килешү төзелгән территория чикләрендә урнашкан булса, җир кишәрлеге бирү турындагы гариза белән әлеге биналар, корылмалар, алар эчендәге бүлмәләр, әлеге төзелеше тәмамланмаган объектның милекчесе яки андый җир кишәрлегенең хокукка ия заты мөрәҗәгать иткән очраклардан кала;<br>9) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге төзелгән территорияне үстерү турында башка зат белән килешү төзелгән территория чикләрендә урнашкан булса яки җир кишәрлеге төзелгән территорияне комплекслы үзләштерү турында башка зат белән килешү төзелгән җир кишәрлегеннән барлыкка килгән булса, әгәр андый җир кишәрлеге федераль әһәмияттәге, региональ әһәмияттәге һәм җирле әһәмияттәге билгеләнештәге объектларны урнаштыру өчен каралган һәм андый җир кишәрлеге бирү турындагы гариза белән күрсәтелгән объектларны төзүгә вәкаләтле зат мөрәҗәгать итсә;<br>10) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге, төзелгән территорияне комплекслы үзләштерү турында башка зат белән килешү төзелгән җир кишәрлегеннән барлыкка килгән яки федераль әһәмияттәге, региональ әһәмияттәге һәм җирле әһәмияттәге билгеләнештәге объектларны урнаштыру өчен каралган территорияне планлаштыру буенча расланган документлар нигезендә төзелгән территорияне үстерү турындагы килешү булса, җир кишәрлеген арендага бирү турындагы гариза белән территорияне комплекслы үзләштерү турында килешү төзегән зат мөрәҗәгать иткән булса, күрсәтелгән объектлар төзелеше буенча әлеге затның йөкләмәсе күздә тотылса;<br>11) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге аукцион үткәрү турындагы хәбәр РФ Җир кодексының 39.11 маддәсенең 19 пункты нигезендә урнаштырылган аукционның предметы булып тора;<br>12) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата аны сату яки аренда килешүе төзү хокукына аукцион буенча РФ Җир кодексының 39.11 маддәсенең 4 пункты 4 пунктчасында каралганча аукцион үткәрү турында гариза керсә, андый җир кишәрлеге РФ Җир кодексының 39.11 маддәсенең 8 пункты нигезендә барлыкка килгән булса һәм вәкаләтле орган тарафыннан РФ Җир кодексының 39.11 маддәсенең 8 пунктында каралган нигезләрдә андый аукцион үткәрүне кире кагу турында карар кабул ителмәгән булса;<br>13) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата шәхси төзелеш, шәхси ярдәмче хуҗалык,бакчачылык, дача хуҗалыгы алып бару яки крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеген гамәлгә ашыру турындагы хәбәр РФ Җир кодексының 39.18 маддәсе 1 пункты 1 пунктчасы нигезендә басылып чыккан һәм урнаштылган булса; | |

| | | |
|---|---|---|
| | 14) җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгәнчә файдалану андый җир кишәрлегеннән файдалану җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән максатларга туры килмәсә, территорияне планлаштыруның расланган проекты нигезендә анда линия объекты урнаштыру очракларыннан кала;<br>15) соратылган җир кишәрлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә расланган, оборона һәм куркынычсызлык ихтыяҗлары һәм вакытлыча әлеге ихтыяҗлар өчен файдаланылмаган җир кишәрлекләре исемлегенә кертелмәгән булса, җир кишәрлеге бирү турындагы гариза РФ Җир кодексының 39.10 маддәсе 2 пункты 10 пунктчасы нигезендә бирелгән очракта;<br>16) гражданнарга яшелчәчелек, бакчачылык алып бару өчен төзелгән коммерцияле булмаган оешмага җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге мәйданы федераль законнар нигезендә билгеләнгән чик күләменнән артып китсә;<br>17) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге, территориаль планлаштыруның расланган документлары һәм (яки) территорияне планлашлаштыру документлары буенча федераль әһәмияттәге, региональ әһәмияттәге яки җирле әһәмияттәге билгеләнештәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән булса һәм җир кишәрлеге бирү турында гариза белән әлеге объектларны төзүгә вәкаләте булмаган зат мөрәҗәгать итсә;<br>18) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге Россия Федерациясе дәүләт программасы, Россия Федерациясе субъектының дәүләт программасы нигезендә биналар, корылмалар урнаштыруга билгеләнгән булса һәм җир кишәрлеге бирү турында гариза белән әлеге биналарны, корылмаларны төзүгә вәкаләте булмаган зат мөрәҗәгать итсә;<br>19) җир кишәрлеген хокукларның әлеге төрендә бирү рөхсәт ителми;<br>20) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата рөхсәт ителгән файдалану төре билгеләнмәгән;<br>21) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге аерым категория җиргә кертелмәгән;<br>22) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеген бирү турында аны бирү алдан килешенмәгән булу хакында карар кабул ителгән, аның гамәлдәге срогы чыкмаган һәм җир кишәрлеген бирү турында гариза белән әлеге карарда күрсәтелмәгән зат мөрәҗәгать иткән булса;<br>23) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен кире кайтарып алынган һәм андый җир кишәрлеген бирүнең гаризада күрсәтелгән максаты ул җир кишәрлеге кире кайтарып алу максатларына туры килмәсә, андый җир кишәрлегендә урнашкан күп фатирлы йортларны авария | |

| | | |
|---|---|---|
| | хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип танылган булу сәбәпле, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен кире кайтарып алынган җир кишәрлекләреннән кала;<br>24) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге чикләре «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәве турында» Федераль закон нигезендә анықланырга тиеш булса;<br>25) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге мәйданы җир кишәрлегенең урнашу схемасында, территорияне межалау проектында яки урман кишәрлекләренең проект документларында күрсәтелгән мәйданнан артып китсә, шул нигездә ун процентган да артмаган шундый җир кишәрлеге барлыкка килсә. | |

4) 3.3.2. пунктта «Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына» сүзләрен «җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

5) 3.3.3 пунктын бетерергә;

6) 3.5.6. пунктта «Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына» сүзләрен «Башкарма комитет Җитәкчесенә» сүзләренә алмаштырырга;

7) 3.5.7. пунктта «Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары» сүзләрен «Башкарма комитет Җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга;

8) 4.2. пунктта «Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары тарафыннан» сүзләрен «Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

9) 4.4. пунктта «Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары» сүзләрен «җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

10) 4 бүлекне түбәндәге эчтәлектәге 4.5 пункты белән тулыландырырга:

«4.5. Муниципаль хезмәт күрсәтүгә гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан контроль Башкарма комитетның муниципаль хезмәт күрсәткәндә муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы ачык эшчәнлеге, тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат һәм муниципаль хезмәт күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге бирү аша гамәлгә ашырыла.»;

11) 5 бүлекнең исемен яңа редакциядә бәян итәргә:

«5. Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук күп функцияле үзәкнең, күп функцияле үзәк хезмәткәрләренең карарларын һәм эш итүләрен (эш итмәүләрен) судка кадәр (судтан тыш) шикаять итү тәртибе»

12) 5.1. пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Муниципаль хезмәт алучылар муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы Башкарма комитетның вазыйфаи затларының карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) карата судка кадәр – Башкарма комитетка, күп функцияле үзәк хезмәткәрләренә карата – күп функцияле үзәк яисә күп функцияле үзәкне гамәлгә куючы булып саналган тиешле дәүләт хакимияте органының (җирле үзидарә органының) ачык-хокукый берәмлегенә шикаять итәргә хокуклы.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы запросын, 210-ФЗ санлы Федераль законның 15.1 маддәсендә күрсәтелгән запросны теркәү срогы бозылу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтүнең срогы бозылу;

3) гариза бирүче тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында,

Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге хокукый актларында каралмаган документларны таләп итү;

4) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге хокукый актларында каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту, әгәр баш тарту өчен нигез федераль законнарда каралмаган һәм алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актлары, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге хокукый актларында каралмаган булса;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) Башкарма комитет, Башкарма комитет вазыйфаи затларының, күп функцияле үзәк, күп функцияле үзәк хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә документларда алар тарафыннан җибәрелгән ялгышлар һәм хаталарны төзәтүдән баш тартулары яисә андый төзәтмәләрнең билгеләнгән срогы бозылу;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирүнең срогы һәм тәртибе бозылу;

9) муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору, әгәр аны туктатып тору өчен федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив-хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге хокукый актларында каралган нигезләр булмаса.»;

13) пункты 5.2. һәм 5.3. пунктларын яңа редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Шикаять язмача рәвештә кәгазь йөрткечтә яки электрон рәвештә бирелә.

Шикаять почта аша, күп функцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрен файдаланып, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайты (http://www.nabchelny.ru.), күп функцияле үзәкнең рәсми сайты, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталы (http://uslugi.tatar.ru/), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru/) аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә алынырга мөмкин.

5.3. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгән көннән алып унбиш эш көне эчендә.

Башкарма комитетның, күп функцияле үзәкнең гариза бирүченең документларын кабул итүдән яисә җибәрелгән ялгышлар һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуын шикаять итү яки андый төзәтмәләргә билгеләнгән срок бозылуны шикаять итү очрагында – аны теркәгәннән алып биш эш көне эчендә.»;

14) 5.4.пунктта:

- 1 пунктчада «Башкарма комитетның муниципаль хезмәткәрен» сүзләреннән соң «Күп функцияле үзәк, аның җитәкчесен һәм (яки) хезмәткәрен» сүзләре белән тулыландырырга;

- 3 пунктчаны «,күп функцияле үзәк, күп функцияле үзәк хезмәткәрен» сүзләре белән тулыландырырга;

- 4 пунктчаны «,күп функцияле үзәк, күп функцияле үзәк хезмәткәрен» сүзләре белән тулыландырырга;

15) 5.7. пунктының 1 һәм 2 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.7. Шикаятьләрне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда кабул ителгән карарны, җибәрелгән ялгышлар һәм хаталар төзәтүне бетерү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясенең норматив хокукый

актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләүләр алынган булса, акча средстволарын мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.»;

16) түбәндәге эчтәлектәге 5.9. һәм 5.10 пунктлары белән тулыландырырга:

«5.9. Шикаятьне тулысынча яки өлешчә канәгатьләндерү очрагында кимчелекне бетерү максатында күрелергә тиешле чаралар билгеләнә.

Шикаятьләрне карау барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре булган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләт бирелгән вазыйфаи зат, булган материалларны, кичекмәстән, прокуратура органнарына җибәрә.

5.10. Гариза бирүчеләр Башкарма комитет, аның вазыйфаи затларының, шулай ук күп функцияле үзәк, күп функцияле үзәк хезмәткәрләренең карараларын, эш итүләрен (эш итмәүләрен) суд тәртибендә Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять итәргә хокуклы.»;

17) 3 нче кушымтаны яңа редакциядә, әлеге карарга 1 нче кушымтада каралганча бәян итәргә;

18) кушымтаны (белешмәне) яңа редакциядә, әлеге карарга 2 нче кушымтада каралганча бәян итәргә;

19) 4 нче кушымтаны яңа редакциядә, әлеге карарга 3 нче кушымтада каралганча бәян итәргә;.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитның
2018 елның 14 августындагы
4569 карарына
1 нче кушымта

«Муниципаль мөлкәттәге җир кишәрлеген мөлкәткә бушлай бирү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмә)»

Гариза бирүченең җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә сатып алу хокукын раслаучы документлар исемлегеннән өземтә

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 11. | Җир кодексының 39.5 маддәсе 1 пунктчасы | Мөлкәткә бушлай | Төзелгән территорияне үстерү турында килешү төзелгән зат | Территория чикләрендә барлыкка килгән, аңа карата аны үстерү турында килешү төзелгән җир кишәрлеге | Төзелгән территорияне үстерү турында килешү<br>*Күчемсез мөлкәт турында ЕГРН нан алынган өземтә (соратылган җир кишәрлеге турында)<br>*Планлаштыруның расланган проекты һәм территориянең расланган межалау проекты<br>*Гариза бирүче юридик зат турында ЕГРЮЛ дан өземтә |
| 12. | Җир кодексының 39.5 маддәсе 2 пунктчасы | Мөлкәткә бушлай | Мөлкәтендә дини яки иганәчелек билгеләнешендәге биналар яки корылмалар булган дини оешма | Дини яки иганәчелек билгеләнешендәге биналар яки корылмалар урнашкан җир кишәрлеге | Гариза бирүченең бинага, корылмага хокукын раслаучы (билгеләүче) документ, әгәр андый бина, корылмага хокук ЕГРН да теркәлмәгән булса<br>*Гариза бирүченең соратылган җир кишәрлегенә хокукын раслаучы (билгеләүче) документ, әгәр андый җир кишәрлегенә |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | хокук ЕГРН да теркәлмәгән булса (җир кишәрлегенә тиешле хокуклар булганда)<br>*Гариза бирүченең (гариза бирүчеләрнең) соратылган җир кишәрлегендә урнашкан барлык бинალары һәм корылмаларының кадастр (шартлы, инвентарь) номерлары һәм тиешле хокукларда гариза бирүчегә караган бина, корылмаларның адреслы ориентирлары күрсәтелгән исемлеге турындагы хәбәре<br>*Күчемсез объект турында (соратылган җир кишәрлеге) турында ЕГРН нан өземтә<br>*Күчемсез объект турында (соратылган җир кишәрлегендә урнашкан бина һәм (яки) корылма турында) турында ЕГРН нан өземтә<br>*Гариза бирүче юридик зат турында ЕГРЮЛ дан өземтә |
| 13. | Җир кодексының 39.5 маддәсе 3 пунктчасы | Мөлкәткә бушлай | Бакчачылык, яшелчәчелек алып бару өчен җир кишәрлеге бирелгән граждannar оештырган коммерцияле булмаган оешма | Гражданнар тарафыннан бакчачылык, яшелчәчелек алып бару өчен коммерцияле булмаган оешмага бирелгән һәм коммерцияле булмаган, оешманың гомуми файдаланудагы мөлкәтенә караган җир кишәрлеген бүлү нәтиҗәсендә | Коммерцияле булмаган оешма органының җир кишәрлеге сатып алу турында карары<br>*Территориянең расланган межалау проекты<br>*Коммерцияле булмаган берләшмәнең оешма һәм территория төзелеше проекты (территориянең расланган межалау проекты булмаган |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | барлыкка килгән җир кишәрлеге | очракта)<br>*Күчемсез объект турында (соратылган җир кишәрлеге) турында ЕГРН нан өземтә<br>*Гариза бирүче юридик зат турында ЕГРЮЛ дан өземтә |
| 14. | Җир кодексының 39.5 маддәсе 3 пунктчасы | Гомуми мөлкәткә бушлай | Бакчачылык, яшелчәчелек алып бару өчен җир кишәрлеге бирелгән гражданнар оештырган коммерцияле булмаган оешма әгъзалары | Гражданнар тарафыннан бакчачылык, яшелчәчелек алып бару өчен коммерцияле булмаган оешмага бирелгән һәм коммерцияле булмаган, оешманың гомуми файдаланудагы мөлкәтенә караган җир кишәрлеген бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән җир кишәрлеге | Гариза бирүченең коммерцияле булмаган оешмада әгъза булуын раслаучы документ<br>*Территориянең расланган межалау проекты<br>*Коммерцияле булмаган берләшмәнең оешма һәм территория төзелеше проекты (территориянең расланган межалау проекты булмаганда)<br>* Күчемсез мөлкәт объекты турында (соратылган җир кишәрлеге турында) ЕГРН нан өземтә<br>*Граждан әгъза булып торган коммерцияле булмаган оешманың ЕГРЮЛ дан өземтәсе |
| 15. | Җир кодексының 39.5 маддәсе 4 пунктчасы | Мөлкәткә бушлай | Россия Федерациясе субъекты законнарында билгеләнгән муниципаль берәмлек территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару яки крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеген гамәлгә | Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару яки крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән һәм рөхсәт ителгән файдалану нигезендә биш елдан артык файдаланылган җир кишәрлеге | * Күчемсез мөлкәт объекты турында (соратылган җир кишәрлеге турында ЕГРН нан өземтә) |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | ашыру өчен алты елдан да артмаган срокка түләүсез жир кишәрлеге бирелгән граждан | | |
| 16. | Җир кодексының 39.5 маддәсе 5 пунктчасы | Мөлкәткә бушлай | Төп эш урыны, белгечлеге буенча Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән муниципаль берәмлекләрдә эшләүче граждан | Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән муниципаль берәмлектә урнашкан, шәхси төзелеш яки шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлеге | Эшкә алу турындагы приказ, хезмәт кенәгәсеннән өземтә яки хезмәт килешүе (контракт)<br>* Күчемсез мөлкәт объекты турында (соратылган җир кишәрлеге турында) ЕГРН нан өземтә |
| 17. | Җир кодексының 39.5 маддәсе 6 пунктчасы | Мөлкәткә бушлай | Өч һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнар | Җир кишәрлеге бирү очраклары Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнә | Җир кишәрлекләре бирү шартларының Россия Федерациясе субъекты законнары нигезендә булуын раслаучы документлар<br>*Күчемсез мөлкәт объекты турында (соратылган җир кишәрлеге турында) ЕГРН нан өземтә |
| 18. | Җир кодексының 39.5 маддәсе 7 пунктчасы | Мөлкәткә бушлай | Федераль закон белән билгеләнгән аерым категория гражданнар һәм (яки) гражданнар тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешмалар | Җир кишәрлеге бирү очраклары Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнә | Җир кишәрлеген Россия Федерациясе законнары билгеләгән нигездә сатып алу хокукын раслаучы документлар<br>*Күчемсез мөлкәт объекты турында (соратылган җир кишәрлеге турында) ЕГРН нан өземтә |
| 19. | Җир кодексының 39.5 маддәсе 7 пунктчасы | Мөлкәткә бушлай | Россия Федерациясе законы белән билгеләнгән аерым категория гражданнар | Җир кишәрлеге бирү очраклары Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнә | Җир кишәрлеген Россия Федерациясе законнары билгеләгән нигездә сатып алу хокукын раслаучы документлар |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Җир кишәрлеген Россия Федерациясе законнары билгеләгән нигездә сатып алу хокукын раслаучы документлар |
| 20. | Җир кодексының 39.5 маддәсе 8 пунктчасы | Мөлкәткә бушлай | Даими (сроксыз) файдалану хокукында һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен билгеләнгән җир кишәрлеге булган дини оешма | Җир кишәрлеге бирү очраклары Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнә | Җир кишәрлеген Россия Федерациясе законнары билгеләгән нигездә сатып алу хокукын раслаучы документлар |

*(1) Җир кишәрлегенә хокук алу турындагы гаризаны кабул итүче Башкарма хакимият органы яки җирле үзидарә органының вазыйфаи заты тарафыннан расланган документлар төп нөсхәдә (әгәр документлар һәркем карарлык булса, күчермәдә) яисә күчермәдә бирелә (җибәрелә).
*(2) Россия Федерациясенең Законнар җыентыгы, 2001, N 44, 4147 маддә.; 2014, N 26, . 3377 маддә.
*(3) "*" символлары белән билгеләнгән документлар дәүләт һәм муниципаль мөлкәттәге җир кишәрлекләрен сату-алуга вәкаләтле орган (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан ведомствоара мәгълүмати үзара эшчәнлек аша соратып алына. Күчемсез мөлкәт объекты турында (соратылган җир кишәрлеге турында) ЕГРН өземтәсе җир кишәрлегенә хокук алу хакындагы гаризага теркәлми һәм әгәр соратылган җир кишәрлеген әле барлыкка китерәсе булса, җир кишәрлеге бирү алдан килешенгән очракта, җир кишәрлеген биргәндә вәкаләтле орган тарафыннан ведомствоара мәгълүмати үзара эшчәнлек аша соратып алынмый. Бинага, корылмага, төзелеше тәмамланмаган объектка хокук федераль закон нигезендә элеге хокукның ЕГРН да дәүләт теркәве үткәрелгән моментка бәйсез рәвештә барлыкка килгән дип саналган очракта, күчемсез мөлкәт объекты турында (соратылган җир кишәрлегендә урнашкан бина, корылма, төзелеше тәмамланмаган объект турында) ЕГРН өземтәсе җир кишәрлегенә хокук алу хакындагы гаризага теркәлми һәм вәкаләтле орган тарафыннан ведомствоара мәгълүмати үзара эшчәнлек аша соратып алынмый.

Башкарма комитетның
2018 елның 8 августындагы
4569 карарына
2 нче кушымта

«Муниципаль мөлкәттәге җир
кишәрлеген мөлкәткә бушлай бирү
буенча муниципаль хезмәтләр
күрсәтүнең административ
регламентына кушымта (белешмә)»

Муниципаль хезмәт күрсәтүгә җаваплы һәм аның үтәлешенә контрольне
гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның
реквизитлары

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 30-55-42 | kancel.chelny@tatar.ru |
| Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы | 30-55-54 | uzioIP@yandex.ru |
| Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы урынбасары | 30-55-54 | uzioIP@yandex.ru |
| Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе җир ресурслары белән идарә итү бүлеге башлыгы | 30-59-72 | uzioIP@yandex.ru |
| Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе җир ресурслары белән идарә итү бүлеге белгече | 30-55-54 | uzioIP@yandex.ru |

Башкарма комитетның
Аппарат Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2018 елның 8 августындагы
4569 карарына
3 нче кушымта

«Муниципаль мөлкәттәге җир
кишәрлеген мөлкәткә бушлай бирү
буенча муниципаль хезмәтләр
күрсәтүнең административ
регламентына 4 нче кушымта»

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең эш эзлеклелеге
блок-схемасы

Гариза бирүче

Әлеге регламентның 2.5 пункты нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы документлар теркәлгән гариза → Гариза, документлар

Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече

Гариза һәм документларны кабул итә һәм терки, мөрәҗәгать итүчегә гаризаның күчермәсен бирә, гариза һәм документларны карау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә → Кабул ителгән һәм теркәлгән, Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән гариза һәм документлар

Башкарма комитет Җитәкчесе

Гариза һәм документларны карый, ҖММИ башлыгына җибәрә → ҖММИ башлыгына җибәрелгән документлар

ҖММИ башлыгы

Гариза белән документларны карый һәм ҖММИ бүлеге башлыгына җибәрә → ҖММИ бүлеге башлыгына җибәрелгән гариза һәм документлар

ЖММИ бүлеге башлыгы

Гариза һәм документларны карый һәм ЖММИ бүлеге белгеченә җибәрә

ЖММИ бүлеге белгеченә җибәрелгән гариза һәм документлар

ЖММИ бүлеге белгече

Гариза һәм документларны хокукый база нормативларын исәпкә алып карый, формалаштыра һәм әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документлар бирелүе турындагы запросларны ведомствоара мәгълүмати үзара эшчәнлек аша электрон формада Федераль салым хезмәтенә һәм дәүләт теркәве, кадастр һәм картография Федераль хезмәтенә җибәрә

Хакимият органнарына җибәрелгән запрослар

ЖММИ бүлеге белгече

Документларны карый һәм өйрәнә, карар проектын әзерли һәм карар проектын килештерүгә җибәрә

Документлар туры килмәгәндә

Муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында ЖММИ бүлеге башлыгына җибәрелгән хат

Документлар туры килгәндә

Архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә җибәрелгән карар проекты


ЖММИ бүлеге башлыгы

Муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турындагы хатны карый һәм килештерә һәм аны ЖММИ башлыгына җибәрә

ЖММИ башлыгы

Муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турындагы хатны карый һәм имзалый һәм аны эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә

Муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында имзаланган һәм эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән хат


Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе
Муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турындагы хатны терки һәм гариза бирүчегә җибәрә
Муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында теркәлгән һәм гариза бирүчегә җибәрелгән хат
Архитектура, шәһәр төзелеше һәм торакны үстерү идарәсе
Карар проектын карый, килештерә һәм хокук идарәсенә җибәрә яисә карар проектына искәрмәләр әзерли һәм әлеге искәрмәләрне ҖММИ га җибәрә
Килештерелгән һәм хокук идарәсенә җибәрелгән карар проекты
Карар проектына искәрмәләрне төзәтә һәм архитектура, шәһәр төзелеше һәм торакны үстерү идарәсенә җибәрә
Хокук идарәсе
Аны карый, килештерә һәм эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә, яисә карар проектына искәрмәләр әзерли һәм ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрә
Килештерелгән, эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән карар проекты
Карар проектына искәрмәләрне төзәтә һәм хокук идарәсенә җибәрә
Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе
Визаларның булуын тикшерә, карар проектын тикшерә, карар проектын бланкта бастыра һәм имзаларга Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә
Башкарма комитет Җитәкчесенә имзаларга җибәрелгән карар проекты

Башкарма комитет Җитәкчесе

Карар проектын имзалый һәм эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә → Имзаланган һәм эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән карар проекты

Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе

Карарны терки һәм җибәрү реестры нигезендә карарның күчермәсен бирә → Җир кишәрлеге бирү турында Башкарма комитет карары

ҖММИ бүлеге белгече

Карар нигезендә җир кишәрлеген кабул итү-тапшыру актын әзерли, аны ҖММИ бүлеге башлыгына килештерүгә җибәрә → ҖММИ бүлеге башлыгына килештерүгә җибәрелгән кабул итү-тапшыру акты

ҖММИ бүлеге башлыгы

Җир кишәрлеген кабул итү-тапшыру актын карый һәм килештерә, аны ҖММИ башлыгына килештерүгә җибәрә → Килештерелгән, ҖММИ башлыгына килештерүгә җибәрелгән җир кишәрлеген кабул итү-тапшыру акты

ҖММИ башлыгы

Кабул итү-тапшыру актын килештерә һәм имзалауга Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә → ҖММИ башлыгы белән килештерелгән, Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән җир кишәрлеген кабул итү-тапшыру акты проекты

Башкарма комитет Җитәкчесе

Кабул итү-тапшыру актын имзалый һәм ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрә → Башкарма комитет Җитәкчесе имзалаган, ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрелгән җир кишәрлеген кабул итү-тапшыру акты проекты

ҖММИ бүлеге белгече

Җир кишәрлеген кабул итү-тапшыру актын имзалау өчен аны гариза бирүчегә яки ышаныч кәгазе буенча аның ышанычлы вәкиленә (расписка белән)

Җир кишәрлеген кабул итү-тапшыру актын имзалау өчен гариза бирүчегә җибәрелгән җир кишәрлеген кабул итү-

Гариза бирүче

Җир кишәрлеген кабул итү-тапшыру актын имзалый һәм теркәү өчен ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрә

ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрелгән җир кишәрлеген кабул итү-тапшыру акты

ҖММИ бүлеге белгече

Җир кишәрлеген кабул итү-тапшыруның имзаланган актын теркәү журналында терки һәм җир кишәрлеген кабул итү-тапшыру актын 3 данәдә гариза бирүчегә яки ышаныч кәгазе буенча аның ышанычлы вәкиленә бирә.

Мөрәҗәгать итүчегә бирелгән җир кишәрлеген кабул итү-тапшыру акты.